Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Советы

КАРАР

30 декабрь 2025ел №8

Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегемуниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 57 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә

Иске Михайловка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының «Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 57 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2018 елның «05» декабрендәге 61 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 9 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 58 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 64 номерлы, 2022 елның 26 июньдә 101 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 109 номерлы, 2025 елның 20 маендагы 120 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаныңисеме | Вазыйфаи оклад (хезмәткәтүләүнең12тәркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 23 192 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесеурынбасары | 22 515» |

1.3. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаныңисеме | Айлыкакчалатабүләкләүкүләме (хезмәткәтүләүнең12тәркеме) |
|---|---|
| Башлык | 23 201 |
| Башлык урынбасары | 16 931» |

2.Әлеге карарны Иске Михайловка авылы Школьная урамы, 43 йорты, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорты, торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныүз өстемдә калдырам.

Иске Михайловка авыл
җирлеге башлыгы

А.Ю.Зарубин